**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**20 май 2019 ел** **№ 203**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 99, 100 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2005 елның 8 декабрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 19 номерлы Карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

3. Кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына җибәрергә.

4. Әлеге Карарны “Волжские зори”, “Идел таннары” газеталарында Дәүләт теркәве үткәннән соң бастырып чыгарырга һәм Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**

2019 елның 20 маендагы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 203 номерлы Карарына кушымта

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 7 маддәнең 1 өлешенең 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “6.2) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, аз санлы халыкларның һәм башка азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;”.

2. 7.1 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 15 пунктчаны өстәргә:

“15) 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.”.

3. 73 маддәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми бастырып чыгару булып аның тулы текстын районда таратыла торган вакытлы матбугатта бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Рәсми челтәр басмасында муниципаль хокукый актның тулы тексты басылып чыккан (урнашкан) очракта, басма басмада аңа күләмле график һәм таблица кушымталар китерелергә мөмкин.”.

4. 15 маддәнең 2 өлешендә:

беренче абзацта “яки район башлыгы” сүзләрен “, район башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Башкарма комитеты җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта “район Башлыгы” сүзләрен “контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга.

5. 26 маддәнең 6 өлешенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюзта катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез милек милекчеләр иптәшлегендә катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш, оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясе органнарында (гамәлгә куючы) район мәнфәгатьләрен, муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләренә) оештыру яисә идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә кире кайтарылмый торган нигездә тәкъдим итү;

федераль законнарда каралган башка очракларда;”.